| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«8» декабрь 2022 № 262

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 13 октябрендәге 200 номерлы «Торак фондының алар биләгән торак урыннарын гражданнарның милкенә тапшыру (торак фондын хосусыйлаштыру) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» 236 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 13 октябрендәге 200 номерлы «Торак фондының алар биләгән торак урыннарын гражданнарның милкенә тапшыру (торак фондын хосусыйлаштыру) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Торак фондының алар биләгән торак урыннарын гражданнарның милкенә тапшыру (торак фондын хосусыйлаштыру) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

а) түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт белән тулыландырырга:

«1.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында муниципаль хезмәтне алдан ук (проактив) режимда бирү очраклары һәм тәртибе каралмаган.»;

б) 2.5.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхесне таныклый торган документ (Россия Федерациясе гражданы паспорты йә шәхесне таныклый торган башка документ) яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә "Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында" 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1 статьясындагы 18

өлешендә каралган мәгълүмати технологияләрдән файдаланып идентификация һәм аутентификация юлы белән;»;

в) 2.10 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 11 июлендәге 52 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы һәм аларны күрсәткән өчен түләүнең иң чик күләмен билгеләүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» карары»;

г) 3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә, гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары бар, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да.»;

д) 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер электрон форма гарызнамәсен тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон рәвештә тутырылган кырының корректлы булмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры гарызнамәнең электрон формасында ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев